СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«12» декабрь 2024 ел** **№ 315**

**Арча район Советының 2024 елның 31 гыйнварындагы 264 номерлы карары (22.05.2024 № 285 үзгәрешләр белән) белән расланган 2024 елга Арча муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законнар, Арча район Советының 2008 елның 27 декабрендәге 224 номерлы карары (14.10.2011 №74, 17.05.2012 №137, 28.05.2015 №342, 12.07.2016 №61, 10.11.2016 №87, 10.11.2017 №152, 19.09.2019 №275 үзгәрешләр белән) белән расланган «Арча муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә нигезендә, муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, Арча район Советы карар бирде:

Арча район Советының 2024 елның 31 гыйнварындагы 264 номерлы карары (22.05.2024 № 285 үзгәрешләр белән) белән расланган 2024 елга Арча муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«III бүлек. 2024 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт исемлегенә түбәндәге эчтәлекле 18-23 пунктлар өстәргә:

**III бүлек. 2024 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт исемлеге**

| № | Мөлкәтнең исеме һәм урнашкан урыны . | Характеристикасы | Фаразланган хосусыйлаштыруны үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 18. | Тәгәрмәчле Белорус 82.1 тракторы | 2013 елда чыгарылган, зәңгәр төстә | ел дәвамында |
| 19. | CHEVROLET NIVA, (дәүләт. номеры Х 110 ВО 116 RUS) | 2015 елда чыгарылган, аксыл-көмеш металлик төсендә | ел дәвамында |
| 20. | Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, Ленин ур., 71 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге булган торак булмаган бина (ФАП) | 117,9 кв. м мәйданлы, бер катлы | ел дәвамында |
| 21. | Форд Фокус, (дәүләт номеры В 048 ХА 716 RUS) | 2012 елда чыгарылган, караңгы-зәңгәр төстә | ел дәвамында |
| 22. | Арча муниципаль районы, Гөберчәк авылы, М. Мәһдиев ур., 72а йорт адресы буенча урнашкан торак булмаган бина | 95,3 кв. м мәйданлы, бер катлы | ел дәвамында |
| 23. | Пежо Боксер (гос. АУ 071 16) | 2013 елда чыгарылган | ел дәвамында |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы сайтында (www.arsk.tatarstan.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г.Нуриев